

Бишенче февральдә «Россия» милли үзәгендә «Белем» Россия җәмгыятенен «Россия – гаиләләр гаиләсе» («Россия – семья семей») марафоны кысаларында 2026 елгы халыкара яшьләр фестивалендә (МФМ-2026) катнашу очен теркәлү башланды. 2026 елнын ин зур яшьләр вакыйгасы 11 сентябрьдән 17 сентябрьгә кадәр Екатеринбургта узачак һәм планетанын киләчәге очен жа-ваплылыкны үз остенә алырга әзер булган ботен донья яшьләренен очрашу мәйданчыгы булачак. Теркәлү 30 апрельгә кадәр сайтта булачак (wyffest.com).

МФМ - 2026да 5 мен россияле һәм 35 яшькә кадәрге 5 мен чит ил гражданы катнашачак. Традиция буенча алар санына яшь олкәннәр генә түгел, 14 яшьтән 17 яшькә кадәрге яшүсмерләр дә керәчәк: 500 – Россиядән һәм 500 - чит илләрдән.

«Президент Владимир Путин башлап жибәргән Россия халыклары бердәмлеге елында Халыкара яшьләр фестивале чын-чынлап берләштерүче вакыйга булачак һәм доньяга илебез мәдәниятенен байлыгын һәм уникальлеген ачык күрсәтәчәк. Фестивальнен топ программасы тәмамланганнан сон, 1000 чит ил кешесе Россиянен 30 тобәгенә Тобәк программасына юл тотачак, шулай ук Абхазия Респуб ликасына да барачак. Без ботен донья яшьләрен Россиядә котәбез – күпполяр доньянын киләчәген безнен белән бергә тозергә әзер булган һәркем очен чиксез момкинлекләр илендә», - дип билгеләде Росмолодежь житәкчесе Григорий Гуров.

Екатеринбургка шулай ук ботен Россиядән 2 мен волонтер 17 функциональ юнәлештә ярдәм итәчәк: логистикадан һәм аккредитациядән алып делегацияләрне озатып йорүгә һәм контент булдыруга кадәр. Топ программа тәмамланганнан сон волонтерлар экспедицияләр форматында, тобәк программасы кысаларында, чит ил делегацияләрен озатып йориячәк.

Волонтерлар корпусына керү очен кандидатларга 16 яшьтән олкәнрәк булырга, волонтерлык һәм ижтимагый эшчәнлек тәжрибәсе, югары кызыксыну дәрәжәсе булырга, чит телләрне белергә, аралашучан булырга, шулай ук командада эшли белергә кирәк. Волонтерлык программасында катнашуга гаризаны Добро. РФ платформасында 2026 елнын 31 мартына кадәр бирергә момкин.

2026 елгы халыкара яшьләр фестивален оештыручылар - Яшьләр эшләре буенча Федераль агентлык һәм Свердловск олкәсе Хокүмәте, вакыйга операторы – Ботендонья яшьләр фестивале дирекциясе.

Фото: Росмолодёжь